Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичүү авыл башкарма комитеты

# КАРАРЫ

26 июнь 2023 ел № 5

Әлмәт муниципаль районы Кичүү авыл башкарма комитетының 2021 елның 8 июненнән 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүү авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 14 апрелендәге 127-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 16 июньдәге 225 номерлы протестын караганнан соң

Кичүү авыл башкарма комитеты
КАРАР БИРДЕ:

1.Әлмәт муниципаль районы Кичүү авыл башкарма комитетының 2021 елның 8 июненнән 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичүү авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау турында»гы карарга (Әлмәт муниципаль районы Кичүү авыл башкарма комитетының 2021 елның 2 августындагы 4 номерлы, 2022 елның 22 октябрендәге 16 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

3 нче бүлекнең 3.6 нчы пунктын "шул исәптән электрон формада" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3 нче бүлекнең 3.8 нче пункт төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Кичүү авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт; Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кичүү авыл
башкарма комитеты җитәкчесе Г.П.Туманова